ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 7

Кәрәкәшле ав. 24 апрель 2024 ел

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 3 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ санлы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 3 санлы карары белән расланган Кәрәкәшле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезмәлә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 18.2 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар катнаша ала.

Әлеге конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 18.2 пунктының 34 пунктчасында каралган бөтен срок дәвамында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25 - ФЗ санлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.»;

1.2. Нигезләмәнең 18 маддәсендәге 18.1 пунктының 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

1.3. 9 маддәнең 9.4. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4. Муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.»;

1.4. 9 маддәсенең 9.3 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддщсендщ каралган анкета;

1.5. Нигезләмәнең 6 маддәсенең 6.1 пунктының 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, йә документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау, алар муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый;

1.6. Нигезләмәнең 5 маддәсенең 5.5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчасы белән тулыландырырга:

"яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - анкетадагы мәгълүматлар).».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет»

мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев